Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында
гражданнар җыены нәтиҗәләре турында
КАРАР

25 ноябрь 2019 ел № 1

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлеге Уставының 13.1 статьясы, «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында гражданнар җыенының беренче, икенче, өченче, дүртенче этаплары тавыш бирү нәтиҗәләре (нәтиҗәләре) турында» 2019 елның 24 ноябрендәге беркетмәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында гражданнар җыены карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылында 2019 елның 20, 21, 22, 23 ноябрендә узган халык җыенын үткәрелгән дип танырга, җыенның нәтиҗәләре - дөрес.

2. «Сез 2020 елда Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының Габдрахман авыл җирлегенең Габдрахман авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм әлеге средстволарны җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:Габдрахман авылында асфальт –бетон юлны ремонтлауга файдалану һәм сметалар төзү һәм техник күзәтчелек үткәрү өчен түләү?» мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Халык җыены нәтиҗәләрен «Альметьевский вестник» газетасында, Габдрахман авылы, Совет урамы, 77 нче йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында бастырырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче
Габдрахман
авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Мотаһиров

Р.05-11256/12
«АБДРАХМАНОВСКИЙ СЕЛЬСКИЙ СОВЕТ»
ИНН 1607002265
КПП 164401001